| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Совет Старомензелябашского<br>сельского поселения<br>Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы<br>Иске Минзәләбаш авыл җирлеге<br>Советы |

---

| | |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ<br>05.04.2023. | КАРАР<br>№ 9 |

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чараларын кертү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, Сарман районы Прокуратурасының 2023 елның 02 мартындагы 02-01-21/2023 номерлы мәгълүматы, Сарман муниципаль районының «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы карар итте:

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының 2020 елның 10 августындагы 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чараларын кертү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 3 пунктның 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;
б) 4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;
в) 5 пунктның 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

г) 6 пунктның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

д) 7 пунктның 1,3 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

е) 11 пунктның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә)» сүзләренә алмаштырырга.

2. «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Советы рәисе

А.Н.Габдрахманов